БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 01 2025 ел № 63

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә алган хәрби җәрәхәт нәтиҗәсендә инвалид калган гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында

Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 16 мартындагы «Россия Федерациясендә социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү һәм халыкны яклау чаралары турында» 121 номерлы Федераль закон нигезендә һәм махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче затларның һәм хәрби хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хезмәт итүче гражданнарның гаиләләренә, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә яки махсус хәрби операциядә катнашу барышында алган хәрби җәрәхәт нәтиҗәсендә инвалид калган гражданнарның гаиләләренә (алга таба – гаиләләр) түбәндәге өстәмә ярдәм чаралары билгеләргә:

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә баланы тәрбияләгән һәм караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү.

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныфларда укучы гаилә әгъзаларын ике тапкыр түләүсез кайнар ризык (иртәнге аш, төшке аш) белән тәэмин итү.

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары карамагындагы мәктәпләрдә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә түгәрәкләрдә һәм өстәмә белем бирү секцияләрендә шөгыльләнгән өчен түләүдән азат итү.

1.4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге музейларга бушлай бару.

1.5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы спорт объектларына - тренажер залы булган «Дулкын» өсте ябулы йөзү бассейнына һәм спорт залларына түләүсез керү.

1.6. Көндезге мәктәп яны лагерьларында ата-аналар взносын түләүдән азат итү.

1.7. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты буйсынуындагы учреждениеләр уздыра торган мәдәният - ял вакытларын уздыру чараларына, мәдәни - тамаша кылу һәм сәнгать өлкәсендәге башка чараларга түләүсез керү.

2. Әлеге карарның 1.7 пунктында каралган ярдәм чарасына хокук алу өчен чарага кадәр биш календарь көннән дә соңга калмыйча оешма кассасына мөрәҗәгать итәргә кирәклеген билгеләргә. Буш урыннар булганда, гаилә әгъзаларына чарага билетлар биреләчәк, буш урыннар булмаган очракта гаилә әгъзаларына оешма чаралары исемлегендә китерелгән башка чараларга барырга тәкъдим ителә.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1.1-1.7 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) И.Ф.Гайнетдиновка, ярдәм чараларын вакытында күрсәтү максатларында, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның балалар саны буенча даими мониторинг алып барырга.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) 2023 елның 22 декабрендәге «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм чаралары турында» 334 нче номерлы карар;

2) 2024 елның 09 февралендәге «Махсус хәрби операциядә катнашучыларның Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният һәм мәгариф учреждениеләре үткәргән (оештырган) чараларга түләүсез баруы турында»77 номерлы карары.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов